ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты таныклыгы һәм «Татарстан Дәүләт Советы депутаты» күкрәк тамгасы, аларның үрнәкләре һәм тасвирламалары турында нигезләмәләр хакында» 2004 елның 26 февралендәге 2643 номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты таныклыгы һәм «Татарстан Дәүләт Советы депутаты» күкрәк тамгасы, аларның үрнәкләре һәм тасвирламалары турында нигезләмәләр хакында» 2004 елның 26 февралендәге 2643 номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 2 (II өлеш); 2007, № 12 (IV өлеш); 2011, № 1 – 2 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтада:

а) 3 пунктта «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары имзасы куелган килеш тапшырыла» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Президенты имзасы куелып тапшырыла» сүзләренә алмаштырырга;

б) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларына таныклыкларны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе тапшыра. Таныклыкны алу турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары таныклыкларын исәпкә алу һәм саклау журналында үз имзасын сала, журнал Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге тарафыннан алып барыла һәм саклана.»;

в) түбәндәге эчтәлекле $5^2$ пункт өстәргә:

«$5^{2}$. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитеты рәисе (рәисе урынбасары) итеп сайланган очракта аңа Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты таныклыгы тиешле вазыйфаны күрсәтеп тапшырыла. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында вазыйфасыннан азат ителгәндә йә башка вазыйфага сайланганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатына шул ук номер белән башка таныклык тапшырыла. Бу очракта Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатының элекке таныклыгын ул Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә тапшыра.»;

2) 4 нче кушымтада «русча Ф.И.АТ. ис.» сүзләреннән соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитеты рәисе (рәисе урынбасары) итеп сайланган очракта таныклыкның эчке уң һәм сул якларында «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты» һәм «Депутат Государственного Совета Республики Татарстан» сүзләреннән соң астарак тиешенчә татар һәм рус телләрендә тиешле вазыйфа күрсәтелә.».

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2019 елның 20 сентябре
№ 38-VI ДС